Тәртип радиосы




# "ҮЗ ИЛЕМДӘ - ҮЗ КӨЕМ" бәйгесе







Тәртип радиосы









"Үз илемдә - үз көем" бәйгесе беренче тапкыр 2021 елда уздырылды. Онытылган җырларны барлауны максат итеп куйган әлеге конкурста Татарстаннан гына түгел, читтә яшәүче йөздән артык үзешчән һәвәскәр җырчы һәм коллективлар катнашты.

Тәртип радиосы









**Бәйгедә катнашу өчен элеккеге татар җырларын музыка уен коралына кушылып яки акапелла җырлап видеога төшерәсе һәм социаль челтәрдәге шәхси аккаунтларга урнаштырасы иде. Шул рәвешле бу җырлы видеолар киң таралыш алды, халкыбызның бәһасез мирасы булган татар җырлары яңа мәйданга чыкты.**

Тәртип радиосы




***Мәртәбәле комиссия әгъзалары: Татарстанның халык артисты Шамил Әхмәтҗанов, Татарстанның халык артисты Фердинанд Сәләхов, әдәбият белгече, галим, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Фоат Галимуллин, җырчы Венера Шәмиева, "Тәртип" радиосының баш мөхәррире Ризәлә Исмәгыйлева барлык видеоларны карап чыкканнан соң, 4 җиңүчене билгеләде.***

Тәртип радиосы




**Җиңүчеләрнең һәркайсына акчалата бүләк тапшырылды. Бүләкләү барышында алар үзләренә җиңү китергән җырларны да башкарып киттеләр. "Уел", "Гөлбакчада", "Тугайларым", "Бик еш кайтам" һәм бәйгегә килгән тагы берничә җыр шулай ук ТӘРТИП радиосы эфирында да яңгырады.**

Тәртип
радиосы




**2022 елда "Үз илемдә - үз көем" конкурсы "Үз өемдә - үз көем" исеме белән дәвам итәчәк. Бу юлы һәвәскәрләр җыр бәйгесен милләтебезнең талантлы гаиләләре арасында уздырырга исәп.**

Тәртип радиосы











**Бәйгенең бүләкләү тантанасын Казан сәхнәләренең берсендә концерт форматында уздыру күзаллана. Чарада җиңүчеләр белән бергә татар эстрадасының җырлы гаиләләре дә катнашачак.**